ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 389-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.В. Тыгин, О.Ю. Николаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 389-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1850-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.В. Тыгин,
О.Ю. Николаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш), № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге, аларны күрсәтү һәм (яисә) башкару капиталь ремонтка кертемнең әлеге Законның 9 статьясы нигезендә билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана, үз эченә Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне ала. Күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә билгеләнә.»;
2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә фасадны җылыту, җылләнми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу юлларын ясау, коммуналь ресурсларны һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүне куллануны исәпләүнең автоматлаштырылган мәгълүмати-үлчәү системаларын

урнаштыру, коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең күмәк (гомумйорт) җайланмаларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) куллануга идарә итү һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр, башка төр хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өстәлергә мөмкин.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Закон проектында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән күрсәтүе һәм башкаруы капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана торган  хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр санына кергән һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне билгеләү карала.

Әлеге үзгәреш Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясына тиешле үзгәреш кертә торган 2022 елның 7 октябрендәге 378-ФЗ номерлы Федераль законнан килеп чыга.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм (яисә) башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнарны таләп итми.